«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2022елның 2 ноябрь №61

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 79 номерлы карарына үзгәреш кертү турында (2018 елның 07 июнендәге 87 номерлы, 2018 елның14 ноябрь 101 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 123 номерлы, 30.09.2020 елның 30 сентябрендәге 6 номерлы карарлар редакциясендә)

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль берәмлекләрнең рәисләре, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.2022 елның 1 октябреннән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаи окладларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 июнендәге, 182 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгели торган вазыйфаларына туры китереп 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, депутатларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәисләре урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләр»

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләү һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләү.

3. 2 нче кушымтада 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Матди ярдәм бала туганда җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе, тантаналы, юбилей датасына (хатын-кызлар өчен 50,55 ел, ир-атлар өчен 60,65 яшь) карата, шулай ук каты авырганда, үлемендә һәм хезмәткәрнең һәм аның якын туганнарының башка бәхетсезлек очракларында акчалата түләү рәвешендә бирелергә мөмкин.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 11 төркем (1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше саны) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17944 |

«Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
«Тәмте авыл җирлеге» Советы рәисе И.А.Зиновьев